**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «19» апреленнән № 163

**«Хуҗалык итүче субъектларга товарларны аз санлы, һәм/яисә Яңа Чишмә муниципаль районының ерак урнашкан авыл торак пунктларына ташу буенча транспорт чыгымнарының бер өлешен Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан компенсацияләү турында»**

**Карар бирәм:**

1. Хуҗалык итүче субъектларга товарларны аз санлы, һәм/яисә Яңа Чишмә муниципаль районының ерак урнашкан авыл торак пунктларына ташу буенча транспорт чыгымнарының бер өлешен Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан компенсацияләү тәртибен (1 нче кушымта) расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «19» апреленнән
163 номерлы карарга
1 нче кушымта

**Хуҗалык итүче субъектларга товарларны аз санлы, һәм/яисә Яңа Чишмә муниципаль районының ерак урнашкан авыл торак пунктларына ташу буенча транспорт чыгымнарының бер өлешен Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан компенсация бирү тәртибе**

1.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 20 декабрендәге 558 номерлы, 2008 елның 08 гыйнварындагы 35 номерлы карарлары белән билгеләнгән Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә аз санлы һәм/яки ерак урнашкан авыл торак пунктлары исемлегенә кертелгән (алга таба - Исемлек) аз санлы, һәм/яисә ерак урнашкан авыл торак пунктларына товар ташу буенча хуҗалык итүче субъектларга Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән транспорт чыгымнарының бер өлешенә компенсацияләү механизмын билгели (алга таба - субсидия).

2. Аз санлы, һәм/яисә ерак урнашкан авыл торак пунктларына товар ташу буенча хуҗалык итүче субъектларга транспорт чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү өчен муниципаль район бюджетында каралган чыгымнарны финанслау Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасы нигезендә бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән лимитлары чикләрендә Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла (алга таба - Учреждение).

3. Яңа Чишмә муниципаль районының административ үзәгеннән аның территориясендә урнашкан торак пунктка кадәр автомобиль юлы озынлыгыннан чыгып, автомобиль ягулыгын сатып алуга чыгымнар өлешендә алар тарафыннан тотылган аз санлы, һәм/яисә ераг урнашкан авыл торак пунктларына (алга таба - торак пунктлар) товар ташу буенча хуҗалык итүче субъектларның транспорт чыгымнары кире юнәлештә яисә товарны фактта алу урыныннан алып торак пунктка кадәр һәм кире юнәлештә һәм автомобиль ягулыгының факттагы бәясенә кадәр, хуҗалык итүче субъектлар әлеге Тәртип таләпләре нигезендә документлар биргән очракта, субсидияләнергә тиеш.

Субсидияләр акциз товарларын китерү чыгымнарына бирелми.

4. Субсидияләр юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр бирүдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарларны аз санлы, һәм/яисә ерак урнашкан авыл торак пунктларына ташуны гамәлгә ашыручы товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә (алга таба - катнашучылар) чыгымнар өлешендә транспорт чыгымнарын каплауга бирелә.

5. Субсидияләр бирүнең максаты - ваклап сату оешмаларын стимуллаштыру һәм Яңа Чишмә муниципаль районының аз санлы, һәм/яисә ерак урнашкан авыл торак пунктларына хезмәт күрсәтү.

6. Субсидияләр бирү шарты булып Яңа Чишмә муниципаль районының аз санлы һәм/яисә ерак урнашкан авыл торак пунктларында ваклап сатуны оештыру буенча хезмәтләр күрсәтү тора.

7. Субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

С= (РхНхЦ) х 50%,

биредә:

С - субсидияләр күләме, сум;

Р - юл кәгазьләре мәгълүматлары буенча транспорт чарасының узган юлы, километр;

Н - Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2008 елның «Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау материаллары куллану нормалары» методик рекомендацияләрен гамәлгә кертү турында, 100 километрга литр» 14 мартындагы АМ-23-р номерлы боерыгы нигезендә нигезендә ягулык тотуның төп нормасы.

«Ц - ягулык-майлау материалларына гамәлдәге бәя, 1 литр өчен сум.

8. Субсидияләр алу өчен, хисап чорыннан соң килүче 10 көннән дә соңга калмыйча, Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетында түбәндәге документларны тапшырырга:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза;

б) Яңа Чишмә муниципаль районының аз санлы, һәм/яисә ерак урнашкан авыл торак пунктларына товар ташу фактын раслый торган транспорт чаралары реестры һәм юл кәгазьләре;

в) субсидияләр бирү өчен белешмә-исәп (1 нче кушымта).

9. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының гомуми бүлеге журналга субсидияләр бирүгә гаризаларны кергән көнне терки;

10. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе килгән гаризаларны Яңа Чишмә муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары эшчәнлеге йомгакларын карау буенча эш төркеменә (алга таба - эш төркеме) җибәрә, ул субсидия алу хокукына ия дәгъвачыларны сайлап алуны гамәлгә ашыра.

11. Эш төркеме документлар һәм материаллар кергән вакыттан алып 5 эш көне дәвамында аларны карый һәм субсидияләр бирү мөмкинлеге турында карар чыгара йә, сәбәпләрне күрсәтеп, субсидияләр бирүдән баш тарта (алга таба - карар).

Эшче төркем карары эш төркеме әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Эш төркеме кирәк булган саен өстәмә мәгълүмат һәм субсидия алырга теләк белдергән катнашучылардан документлар соратып ала.

12. Эшче төркемнең карары әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә беркетмә белән рәсмиләштерелә.

13. Башкарма комитет бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм субсидияләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районы буенча Казначылык департаментында ачылган шәхси счетларыннан катнашучыларның субсидия алу турындагы шартнамә нигезендә субсидияләр алучыларны исәп-хисап счетларына күчерә.

14. Субсидия алучы ай саен хисап аеннан соң килүче айның 10 числосына кадәр Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында әлеге Тәртип нигезендә район бюджетыннан кайтарылырга тиешле җитештерү чыгымнары турында хисап бирә.

15. Бирелгән субсидияләрне максатчан билгеләнеше буенча файдаланмау фактларын ачыклау һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр һәм субсидияләр алу өчен документлар тапшыру буенча хәбәрнамә алу датасыннан 60 көн эчендә Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

16. Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты керемена ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта, күрсәтелгән чараларны мәҗбүри рәвештә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләттерелергә тиеш.

17. Субсидия алучыларның тәкъдим ителгән документларының дөреслеге, коррупциягә каршы законнарны үтәү өчен җаваплылык Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет Палатасының, вазыйфаи затларына йөкләнә. Хокук бозучыларга гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла.

18. Бүлеп бирелгән акчаларның максатчан һәм нәтиҗәле кулланылуын тикшереп тору Яңа Чишмә муниципаль районының контроль-хисап Палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
эшләре белән идарә итүче М.Д. Губкина

Хуҗалык итүче субъектларга
товарларны аз санлы, һәм/яисә
Яңа Чишмә муниципаль районының
ерак урнашкан авыл торак
пунктларына ташу буенча транспорт
чыгымнарының бер өлешен
Яңа Чишмә муниципаль районы
бюджетыннан компенсация бирү
тәртибенә
1 нче кушымта

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга Яңа Чишмә муниципаль районы товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләренә чыгымнарны каплау өчен белешмә-исәп.

| Оешма исеме | Транспорт чарасының моделе, маркасы, модификациясе | Транспорт чарасы узган юл (км. ) | Ягулык тоту нормасы л/100 км. | Бәясе - ягулык-майлау материаллары. сум /л | ягулык-майлау материаллары чыгымы сум | Субсидияләр суммасы, мең сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
эшләре белән идарә итүче М.Д.Губкина

Хуҗалык итүче субъектларга
товарларны аз санлы, һәм/яисә
Яңа Чишмә муниципаль районының
ерак урнашкан авыл торак пунктларына
ташу буенча транспорт чыгымнарының
бер өлешен
Яңа Чишмә муниципаль районы
бюджетыннан компенсация бирү
тәртибенә
2 нче кушымта

Яңа Чишмә муниципаль районының
ТР МК 2006 елның 20 декабрендәге 558 номерлы, 2008 елның 08
гыйнварындагы 35 номерлы карарлары белән билгеләнгән исемлегенә кергән
халык саны аз һәм хезмәткә сәләтсез торак пунктлары

1. Бакташ ав.
2. Благодаровка ав.
3. Сөлчә-Баш ав.
4. Татар Әлкине ав.
5. Гарь пос.
6. Өргәнчә ав.
7. Андреевка ав.
8. Горшково ав.
9. Екатериновка ав.
10. Яңа урнашкан Лебедка ав.
11. Яңа Иванаево ав.
12. Рус Чабаксары ав.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
эшләре белән идарә итүче М.Д.Губкина